ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.03.2022**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 568**

«Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары мөлкәтен тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 июлендәге 1653 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 февралендәге 92 номерлы карарын үтәү йөзеннән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары мөлкәтен тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 13 июлендәге 1653 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары мөлкәтен тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1 пунктының икенче һәм җиденче абзацларында «көнкүреш» сүзен «коммуналь» сүзенә алмаштырырга;
1.2. 2.3 пунктындагы 2 нче таблицаның «Каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү» юлында «көнкүреш» сүзен «коммуналь» сүзенә алмаштырырга;
1.3.2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.5. Коммуналь хезмәтләргә чыгымнар күләме $\left(K_{vf}^{t}\right)$ түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_{vf}^{t}=\left(P_{qvf}^{t}+P_{cwvf}^{t}+P_{hwvf}^{t}+P_{canvf}^{t}+P_{elvf}^{t}+P_{htvf}^{t}\right)\times R_{ni},$$

биредә:

$P_{qvf}^{t}$ - җылылык өчен түләү күләме;

$P_{cwvf}^{t}$ - салкын су белән тәэмин итү өчен түләү күләме;

$P_{hwvf}^{t}$ - кайнар су белән тәэмин итү өчен түләү күләме;

$P_{canvf}^{t}$ - су чыгару өчен түләү күләме;

$P_{elvf}^{t}$ - электр белән тәэмин итү өчен түләү күләме;

$P_{htvf}^{t}$ - каты коммуналь калдыкларны чыгарган һәм утильләштергән өчен түләү күләме;

$R_{ni}$ - проект егәрлеге 1 224 урынга һәм аннан да күбрәк булган 2018 елның сентябреннән файдалануга тапшырылган гомуми белем бирү оешмалары өчен төзәтмә коэффициенты 1,3 кә тигез.

Гомуми белем бирү оешмасында җылылык өчен түләү күләме $P_{qvf}^{t}$ түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{qvf}^{t} = Sq_{v}^{t} \times N_{gvf}^{t} \times T_{q\min},$$

биредә:

$Sq_{v}^{t}$ - 1 нче таблица нигезендә билгеләнә торган бер тәрбияләнүченең мәйданын тәэмин итү нормативы;

$N_{gvf}^{t}$ - 2 нче таблица нигезендә җылылык энергиясен куллану нормативы;

$T_{q\min}$ - законнар нигезендә билгеләнгән җылылык энергиясенә Татарстан Республикасы буенча минималь тариф.

Салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү, су чыгару, электр белән тәэмин итү, каты коммуналь калдыкларны чыгару һәм утильләштерү өчен түләү күләме $P_{cw,hw,can,el,lit_{vf}}^{t}$ түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{cw,hw,can,el,lit_{vf}}^{t} = N_{cw,hw,can,el,lit_{vf}} \times T_{cw,hw,can,el,lit_{\min}},$$

биредә:

$N_{cw,hw,can,el,lit_{vf}}$ - салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү, су чыгару, электр белән тәэмин итү, каты коммуналь калдыкларны чыгару һәм утильләштерү нормативы 2 нче таблица нигезендә;

$T_{cw,hw,can,el,lit_{\min}}$ - Татарстан Республикасы буенча салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү, суларны чыгару, электр белән тәэмин итү, каты коммуналь калдыкларны чыгару һәм утильләштерүгә законнар нигезендә билгеләнгән минималь тариф.";

1.4 2.6 пунктында :

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$Z_{mob}$ - Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы мәгариф оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә нигезендә кабул ителә торган хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт өчен түләүгә чыгымнар";

1.5 2.7 пунктының җиденче абзацында «көнкүреш» сүзен «коммуналь» сүзенә алмаштырырга;

1.6 2.12 пунктта

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$О_{Тред}$ - Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары нигезендә билгеләнә торган педагогик персоналның хезмәте өчен түләүгә чыгымнар";

1.7 2.12 пунктта :

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$О_{Тобсл}$ - Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары нигезендә билгеләнә торган бассейнның хезмәт күрсәтүче персоналына хезмәт өчен түләүгә чыгымнар";

1.8 3.1 пунктының беренче абзацында «көнкүреш» сүзен «коммуналь» сүзенә алмаштырырга;

1.9 пунктының сигезенче абзацында «көнкүреш» сүзен «коммуналь» сүзенә алмаштырырга.

2. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев